Мәктәп балаларын гражданлык-патриотик рухта тәрбияләv максаты белән һәр елның февраль аенда Атюрьево районы Усть-Рахмановка гомуми белем бирv урта мәктәбендә Батырлык Дәресләре vткәрәбез.
Балалар халык батырлыклары турында хәбәрдар булырга, vз батырларын танып белергә тиеш, чонки сугыш шаһитларынын сафы коннән-кон сирәгәя бара. Олкән буын яшь буынга Жинvнен нинди бәя белән яулануы, Афган, Чечня һәм башка интернациональ сугыш юлларын vткән сугышчылар турында сойләргә тиеш.

Ветераннар ихтирамга һәм хормәткә лаек кешеләр, алар кешеләргә һәм vз Ватаннарына хезмәт итvдә олге (пример) булып торалар. Шунысы шатлыклы, ветераннар белән мондый очрашуларны Усть-Рахмановка мәктәбендә һәр елны vткәрәбез, чонки без бvген балалар кvнелендә патриотик рухта имин нигез булдырабыз.
Быел да очрашуга тылда, сугыш конфликтларында катнашучыларны, Россия армиясе сафында хезмәт иткән якташларыбызны чакырабыз, дидем. Мәктәптә шундый стендлар да эшләп элдек: Боек Жинvнен 72 яшьлегенә, Боек Ватан сугышында батырларча вафат булган авылдашларыбызга багышлап «Ә иртәгә сугыш иде…», Афганда һәм Тоньяк Кавказда кvрсәткән батыр егетләребезгә багышлап «Алар сугышны кvргән», «18 яшьлек солдатлар» дип формалаштырып элдек.
Чаралар кысасында 5-7 сыйныф житәкчеләре «Тормышта батырлыкка урын бар» дигән класс сәгатьләрендә укучылар Боек Ватан сугышыннан алып бvгенгә кадәр булган яшьтәшләре батырлыклары белән танышалар, газета-китап битләреннән укып батырлар турында чыгыш ясыйлар, vз тормышларыннан – кем суга батучыны коткарган, кем янгыннан чыгарганнар турында ишеттерәләр. Бер cvз белән әйткәндә, бvген дә батырлык очен урын барлыгы турында сойлиләр.
6 сыйныф укучысы Саида Байбековадан «Сезнен гаиләдә февраль аенда ничә бәйрәм бар?» дип сорагач: «Оч. Әтиемнен туган коне -26 февральдә, 23 февраль - Ватан Сакчылары Коне һәм 15 февраль – Афганистаннан Совет Армиясе чыккан кон. Анда минем әтием Абдул-Рякип иде», - диде.

[redacted]